**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 15 сентябрь № 676

г. Казань

Озак вакытлы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразын эшләү һәм раслау тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 170[1] статьясы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 52[1] статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Озак вакытлы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразын эшләү һәм раслау тәртибен расларга.
2. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\676.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 15 сентябрь, 676 нчы карары белән расланды

Озак вакытлы чорга Татарстан Республикасының
бюджет фаразын эшләү һәм раслау
тәртибе

1. Әлеге Тәртип озак вакытлы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразын (алга таба – Бюджет фаразы) эшләү, раслау кагыйдәләрен, аның гамәлдә булу вакытын, шулай ук составына һәм эчтәлегенә таләпләрне билгели.

2. Бюджет фаразы һәр алты ел саен унике һәм аннан күбрәк елларга эшләнә.

Бюджет фаразын эшләү (үзгәртү) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан озак вакытлы чорга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразы (фараз үзгәрешләре) (алга таба – Озак вакытлы фараз, Озак вакытлы фараз үзгәрешләре) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Бюджет фаразына үзгәрешләр аның гамәлдә булу вакытын озайтмыйча кертелә ала.

3. Бюджет фаразы үз эченә түбәндәгеләрне ала:

агымдагы чорда Татарстан Республикасының консолидацияләнгән бюджетын үтәүнең төп йомгаклары, Бюджет фаразын формалаштыру шартлары;

Озак вакытлы фараз вариантларының параметрлары тасвирламасы һәм Озак вакытлы фараз вариантын Бюджет фаразы максатлары өчен база буларак сайлауны нигезләү;

озак вакытлы чорда бурычлар, салымнар һәм бюджет сәясәтен төп формалаштыру юллары;

сайланган сценарийны исәпкә алып, Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты һәм Татарстан Республикасы бюджетының төп үзенчәлекләре фаразы, шул исәптән гамәлдә булу чорына Татарстан Республикасының дәүләт программаларын тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү күрсәткечләре (әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымта нигезендәге форма буенча).

4. Бюджет фаразын (Бюджет фаразы үзгәрешләрен) формалаштыру максатларында, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына түбәндәгеләрне җибәрә:

Озак вакытлы фараз (Озак вакытлы фараз үзгәрешләре) параметрларын һәм аларга аңлатма язуын – агымдагы финанс елының 22 июленә кадәр;

Озак вакытлы фаразның (Озак вакытлы фараз үзгәрешләренең) тәгаенләштерелгән параметрларын һәм аларга аңлатма язуын – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразын караган көннән соң биш эш көненнән артмаган вакыт эчендә.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы:

агымдагы финанс елының 30 сентябренә кадәр чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектына материаллар составында Бюджет фаразы (Бюджет фаразы үзгәрешләре) проектын эшли һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрә, Татарстан Республикасы дәүләт программаларын тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү күрсәткечләреннән тыш.

Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы рәсми басылып чыккан көннән соң 30 көннән артмаган вакыт эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Бюджет фаразын (Бюджет фаразы үзгәрешләрен) раслау турында карар проектын эшли һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына каравына кертә.

6. Бюджет фаразы (Бюджет фаразы үзгәрешләре) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы рәсми басылып чыккан көннән соң ике айдан артмаган вакыт эчендә раслана.

F:\KARAR\2015\676_1.docx

Озак вакытлы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразын эшләү һәм раслау тәртибенә кушымта

## Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты һәм Татарстан Республикасы бюджетының төп үзенчәлекләре фаразы

(млрд.сум)

| Төп үзенчәлекләр исеме | _ел | | _ел | | _ел | | _ел | | _ел | | _ел | | _ел | | _ел | | _ел | | _ел | | _ел | | _ел | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы-ның берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | 2 | | 3 | | 4 | | 5 | | 6 | | 7 | | 8 | | 9 | | 10 | | 11 | | 12 | | 13 | |
| КЕРЕМНӘР, шул исәптән: | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Салым һәм салым булмаган | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Кире кайтарылмый торган күчерүләр | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| ЧЫГЫМНАР, шул исәптән: | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Татарстан Республикасының дәүләт программаларын финанслар белән тәэмин итү | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| ДЕФИЦИТ | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |